# МӘМӘШИР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

15 июнь 2022 ел №19

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җтрлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында Мәмәшир авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 ноябрендәге 44 номерлы карары белән расланган Нигезләмәнең 6 пунктындагы в пунктчасына үзгәреш кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 1 апрелендәге 90-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Мәмәшир авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәширавыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җтрлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында Мәмәшир авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 ноябрендәге 44 номерлы карары Мәмәшир авыл җирлеге Советның 2015 елның 15 июнендәге 26 номерлы, 2021 елның 27 июлендәге 15 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) белән расланган Нигезләмәнең 6 пунктындагы в пунктчасына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

«, акцияләр» сүзен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Җирлек башлыгы И.Г.Әхмәтҗанов